ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына һәм «Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 87-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына һәм «Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 87-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2025 елның 11 июне
№ 300-VII ДС

проект

Татарстан
Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына һәм**
**«Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен**
**оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында»**
**Татарстан Республикасы Законының**
**2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

**1 статья**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 2 өлешенең 14 пунктына (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш); 2013, № 3, № 6 (II өлеш), № 10, № 12 (I өлеш); 2014, № 10 (I өлеш); 2015, № 6 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 1 – 2, № 6 (III өлеш); Татарстан Республикасы законнары җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (часть I), № 50 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш); 2023, № 48 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 73 (I өлеш); 2024, № 45 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2025, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), «, ләкин 10 елдан күп булмаган вакытка» сүзләрен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

«Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» 2017 елның 2 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына (Татарстан Республикасы законнары җыелмасы, 2017, № 94 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш); 2024, № 56 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлешкә «, әгәр әлеге статья белән башкасы каралмаган булса» сүзләрен өстәргә;

2) 2 өлештә «2025 елга кадәр (бу елны кертеп)» сүзләрен «махсус инвестиция проекты гамәлдә булган чорга» сүзләренә алмаштырырга;

3) 3 өлештә «, 2» санын төшереп калдырырга;

4) түбәндәге эчтәлектәге $3^1$ өлешне өстәргә:

«$3^1$. Әлеге статьяның 2 өлешендә билгеләнгән салым ставкасы, күрсәтелгән инвестиция проектын гамәлгә ашыру кысаларында гамәлгә ашырыла торган эшчәнлектән алынган (тотылган) керемнәрне (чыгымнарны) һәм башка эшчәнлекне гамәлгә ашырганда алынган (тотылган) керемнәрне (чыгымнарны) аерым исәпкә алу шарты белән, аңа мөнәсәбәттә махсус инвестиция контракты төзелгән инвестиция проектын гамәлгә ашыру кысаларында гамәлгә ашырыла торган эшчәнлектән салым базасына карата кулланыла.»;

5) 4 өлешне үз көчен югалткан дип танырга.

**3 статья**

Әлеге Закон 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына һәм**
**«Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен**
**оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы закон проектына**

# АҢЛАТМА

«Россия Федерациясендә сәнәгать сәясәте турында» 2019 елның 2 августындагы 290-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы $2^1$ өлеше нигезендә махсус инвестиция контрактларын җайга салу өлешендә автомобиль сәнәгатендә махсус инвестиция контрактының гамәлдә булу вакытын 2033 елның 31 декабренә кадәр озайту мөмкинлеге каралган.

Хәзерге вакытта законнарда махсус инвестиция контрактларында катнашучы йөк автомобиль транспорты чараларын җитештерүчеләр өчен мөлкәткә салым буенча һәм оешмалар табышына салым буенча салым ташламалары каралган.

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы белән мөлкәткә салым буенча ташламалар махсус инвестиция контрактының гамәлдә булу срогына бирелә, әмма 10 елдан да артыгракка түгел.

«Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» 2017 елның 2 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба - 87-ТРЗ номерлы Закон) нигезендә табышка салым буенча ташламалы ставканы куллану 2025 елны да кертеп каралган.

Моңа бәйле рәвештә, шулай ук Татарстан Республикасына инвесторларны җәлеп итүне стимуллау максатларында бер як булып Россия Федерациясе белән беррәттән Татарстан Республикасы да тора торган махсус инвестиция контрактларында катнашучы йөк автомобиль транспорты чараларын җитештерүчеләр өчен салым ташламалары бирү срогын махсус инвестиция контрактының гамәлдә булу срогына озайту карала.

Моннан тыш, 87-ТРЗ номерлы Законның 2 статьясына аңа мөнәсәбәттә махсус инвестиция контракты төзелгән инвестиция проектын гамәлгә ашыру кысаларында гамәлгә ашырыла торган эшчәнлектән салым базасына салым ставкасын куллану шартын күздә тоткан $3^1$ өлеш өстәлә.

87-ТРЗ номерлы Законның 2 статьясындагы 4 өлешенең гамәлдә булу вакыты 2023 елның 1 гыйнварына кадәр генә булганлыктан, закон проектының әлеге өлеше үз көчен югалткан дип танылa.

Моннан тыш, 87-ТРЗ номерлы Законга юридик-техник характердагы үзгәрешләр кертелде.

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына һәм**
**«Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен**
**оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы закон проектын**

# ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына һәм «Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.

Йөк автомобиль транспорты чараларын җитештерүче махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен оешмалар мөлкәтенә салым буенча ташламалар суммасы 2029 елдан башлап 2033 елга кадәрге чор өчен якынча бәяләү буенча 31,5 млн сум, оешмалар табышына салым буенча 2026 елдан 2033 елга кадәрге чор өчен – 4414,67 млн сумтәшкил итәргә мөмкин.

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына һәм**
**«Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

# ИСЕМЛЕГЕ

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына һәм «Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.